**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

21 март 2025 ел № 8 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район
Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр
һәм эшкуарлык буенча Даими комиссиясе
составына үзгәрешләр кертү турында

10 нчы Кәрәкәшле сайлау округы депутаты Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улының Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга, 14.03.2025 елда үз теләге белән отставкага китүенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча Даими комиссиясе әгъзасы, 10 нчы Кәрәкәшле сайлау округы депутаты Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улын Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча Даими комиссиясе составыннан чыгарырга.
2. 6 нчы Акбаш сайлау округы депутаты Сәхибуллина Илһамия Ринат кызын — Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча Даими комиссиясе әгъзасы итеп сайларга.
3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы - З.В.Ильясов